КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 29 март г.Казань № 206

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 сентябрь, 879 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 сентябрь, 879 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 14 декабрь, 1228 нче, 2022 ел, 1 август, 739 нчы, 2022 ел, 15 декабрь, 1331 нче, 2023 ел, 6 апрель, 420 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибендә:

1 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен

югалкан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

17 пунктның унөченче абзацына «мөһере белән» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипкә кушымтада «М.У.» аббревиатурасыннан соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү комиссиясе составында:

комиссия составыннан А.Д.Гариповны чыгарырга;

комиссия составына Фатыйхов Илдар Рәзин улын - Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасарын кертергә, аны комиссия рәисе урынбасары итеп расларга;

Зарипов Раушан Булат улы  вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы».

2. Бу карар (бу карарның 2024 елның 1 июненнән үз көченә керә торган 1 пунктындагы дүртенче - бишенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин